

Җир йөзенә Яңа еллар килә,

Яңа тылсым керә һәр өйгә.

Могҗизага төреп бар дөньяны,

«Җем-җем» итеп карлар сибеләә.

Аклык, сафлык сөргән тирә-юньне,

Сихри көчкә ия булган төн.

Әкияти тылсым безне чорнап ала,

Изге теләк тели бүген һәркем.

Яңа елның алсу таңы безгә,

Иксез-чиксез бәхет китерсен.

Якты өмет баглап алга атлыйк,

Яңа сулыш сихәт иңдерсен.